ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**20.04.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 959**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 04 октябрендәге «Җәмәгать транспорты хезмәтләренең электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2417 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 20 мартындагы «Аерым категориядәге гражданнар өчен Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы бюджетыннан аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 210 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 04 октябрендәге «Җәмәгать транспорты хезмәтләренең электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2417 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 03 декабрендәге 3088 номерлы, 2021 елның 29 декабрендәге 3427 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Карарның 4.2 пунктындагы икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Комиссиянең персональ составы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе белән раслана. Комиссия әгъзалары саны кимендә 5 кеше булырга тиеш»;

1.2 Карарның 4.2 пунктындагы дүртенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзалары санынннан кимендә 2/3 катнашса, хокуклы булып санала. Комиссия әгъзалары аның утырышында алмаштыру

хокукыннан башка катнаша. Комиссия әгъзасы, утырышта үзе булмаса, карала торган мәсьәләләр буенча ул язма рәвештә фикерен бәян итәргә хокуклы».

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына интернет челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 3 мартыннанннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев